ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина**

# АВЫЗ КҮРКЕ – ТЕЛ

МЕТОДИК ӘСБАП

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен

Казан
2021

**УДК 811.512.145**
**ББК 81.2-9**
**Ш 92**

*Методик әсбап*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында*
*эшләнде*

*«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020 – 2024 еллар)»*
*Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында*
*әзерләнде һәм нәшер ителә*

**Шәкүрова М.М.**
**Ш 92** **Авыз күрке – тел.** Методик әсбап: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. – Казан, 2021. – 40 б.
ISBN 978-5-93091-395-8

Методик әсбапта мәктәпкә әзерлек һәм зурлар төркемнәре өчен Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты таләпләре нигезендә төзелгән материал тәкъдим ителә. Әсбап 6–7 яшьлек балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә, татар теле укытучыларына ярдәмлек буларак әзерләнде.

УДК 811.512.145
ББК 81.2-9

**ISBN 978-5-93091-395-8**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2021
© Шәкүрова М.М., 2021
© Гыйниятуллина Л.М., 2021

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Әлеге методик ярдәмлек балалар бакчасында 6–7 яшьлек балалар белән эшләүче татар теле тәрбиячеләре, татар теле укытучылары өчен әзерләнде. Ярдәмлек мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телләрен баету, туган (татар) телдән башлангыч мәгълүмат бирү мәсьәләләрен үз эченә ала.

Баланың сөйләм телен үстерү юнәлешендә төп бурычлар – сөйләм һәм тел культурасы нигезләрен формалаштыру, бала сөйләменең төрле якларын камилләштерү; аларны сәнгать, әдәбият, мәдәнияткә тарту өчен шартлар тудыру.

Баланың сөйләм теленең байлыгы башка кешеләр, дуслары белән аралаша белүендә, сөйләүченең сүзен тыңлый, кабул итә белүендә, тыңлаган мәгълүматка карата үз фикерен җиткерә алуында чагыла.

Тәрбияче балаларның аралашу мөмкинлекләрен стимуллаштырырга, мәсәлән, төрле рәсемнәр, хикәяләр буенча фикер алышуда үз фикерләрен җиткерергә ярдәм итәргә тиеш. Сөйләм күнекмәләре (диалогик һәм монологик) изоляцияләнгән процесс түгел, ул аралашу барышында табигый рәвештә формалаша: яшьтәшләре, өлкәннәр белән караган мультфильм, укыган әкият, шигырь турында фикер алышканда, төрле уеннарда катнашканда, үзара аралашканда һ.б.

Шулай итеп, сөйләм үсешен стимуллаштыру белем бирү барышында педагогик эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә көн саен тормышка ашырылырга тиеш. Тәрбиячеләр яттан шигырьләр өйрәтү, тизәйткечләр әйтү, җырлар җырлау, уеннар оештыру аша балаларның сөйләм телләрен баеталар, камилләштерәләр.

Методик ярдәмлектә темалар 4 лексик блокка бүлеп бирелде: «Мин», «Әйләнә-тирә дөнья», «Туган илем», «Татар дөньясы». Блоклар эчендәге лексик темалар «Телнең күрке – сүз» методик ярдәмлегендәге темалар белән бәйләп алып барыла. Тәрбиячеләргә шушы ике ярдәмлек белән параллель рәвештә эшләргә тәкъдим ителә. Һәр ярдәмлек үз эченә егерме өчәр шөгыльне берләштерә.

## МИН

БЕРЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Безнең гаилә

*[а°] һәм [а] авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигъри юлларны ике тапкыр укып чыга.** Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

***Безнең гаилә***

Әткәй, әнкәй, мин, апа, әби, бабай һәм бер песи –
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе.

*Габдулла Тукай*

1) Синең бабаең бармы?
2) Синең әбиең бармы?
3) Синең исемең ничек?
4) Синең әтиеңнең исеме ничек?
5) Синең әниеңнең исеме ничек?
6) Синең фамилияң ничек?

**2. Тәрбияче *апа, бабай* сүзләрен әйтә, балалар аның артыннан кабатлыйлар.**

**3. Тәрбияче балаларга уенчык песи күрсәтә һәм песи баласына *а* хәрефе кергән кушаматлар уйларга тәкъдим итә.** (Матуркай, Мыраужан)

**4. Тәрбияче шигъри юлларны бер тапкыр укып чыга.** Икенче тапкыр укыганда берәр юллап укый, балалар аның артыннан кабатлыйлар. Тәрбияче *бакча, барасы, бар, болгап, каласы, бакчада, барам, сагынып кайтыр* сүзләрендә балаларның [а°] авазын дөрес әйтүләрен тикшерә, хаталар булса, төзәтә.

***Минем эш***

Әни белән бик рәхәт тә,
Бакчага барасы бар.
Ул киткәндә тәрәзәдән
Кул болгап каласы бар.

Мин дә иртән эшкә китәм –
Бакчада минем эшем.
Барам, кичен әниемне
Сагынып кайтыр өчен.

*Йолдыз*

**5. Тәрбияче җөмләләрне бер тапкыр укый.** Икенче тапкыр укыганда, балаларны үзе артыннан кабатлата.

Мин бабайны яратам.
Мин әтине яратам.
Әби мине ярата.
Әни мине ярата.
Мин әнине сагынам.

**6. Тәрбияче рәсемнәр ярдәмендә сораулар бирә.** Балалар чиратлап сорауларга җаваплар бирәләр.

*Тәрбияче җиңел машина рәсеме күрсәтә. Машина сүзендә [a°] авазының дөрес әйтелүенә игътибар итәргә кирәк.*

Син бакчага нәрсә белән киләсең?

*Тәрбияче автобус рәсеме күрсәтә. Рус теленнән кергән сүзләрдә [a] авазының әйтелүенә игътибар итү сорала.*

Әни эшкә нәрсә белән бара?

**7. Тәрбияче табышмаклар әйтә.** Балалар җавапны әйткәч, җиләк-җимешләрнең рәсемнәрен күрсәтә.

1) Алма дисәң дә алалар, нәрсә соң ул, балалар? *(Алма)*

2) Үзе шардай, эче кандай, тәме балдай. *(Карбыз)*

3) Кызыл төймә таптым, авызыма каптым. *(Җир җиләге)*

**8. Тәрбияче, [a°], [a] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү максаты белән, сүзләрне кабатлата.**

Алма, слива, карбыз, шар, балалар, витамин, груша

ИКЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Безнең өй

[ә] *авазын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигъри юлларны ике тапкыр укып чыга.** Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

***Әби хәйләсе***

Үзем укый белмәсәм дә,
Мин әкият яратам.
– Сөйлә, сөйлә инде, – диеп,
Әбине аптыратам.

Ул таба берәр хәйлә.
Мине белми ди мәллә?
Әнә диванда ята.
– Юк, – ди, – тешем авырта.

*Йолдыз*

1) Нәрсә ул хәйлә?
2) Сиңа әкиятне кем сөйли?
3) Син нинди әкиятләр беләсең?
4) Син хәйләли беләсеңме?

**2. Тәрбияче *ә* хәрефе кергән сүзләрне кабатлата.**
Әби, әкият, хәйлә, әнә

**3. Тәрбияче шигъри юлларны бер тапкыр укып чыга.** Икенче тапкыр укыганда берәр юллап укый, балалар аның артыннан кабатлыйлар. Тәрбияче сүзләрдә балаларның [а], [ә] авазын дөрес әйтүләрен тикшерә, хаталар булса, төзәтә. Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

***Кайт, песием!***

Ачтым өйнең ишеген –
Чыкты качты песием.
Күр әле син бу мутны –
Җирән матур койрыкны!

Эзләдем, арып беттем,
Әллә кайларга җиттем.
Юк кына бит песием,
Инде хәзер нишлием?!

*Фирая Зиятдинова*

1) Песи нинди?
2) Песи кая китә?
3) Синең песиең бармы?
4) Сездә йорт хайваннары бармы?
5) Син песиләр яратасыңмы?
6) Син этләр яратасыңмы?

**4. Тәрбияче табышмаклар әйтә.** Балалар табышмакларның җавапларын әйткәч, әлеге йорт хайванының рәсемен күрсәтә.

Мыеклы да койрыклы,
Мендәр өстендә йоклый. *(Песи)*

Безнең өч дустыбыз бар:
Берсенә утырып йөрибез,
Икенчесе сөт эчертә,
Өченчесе йорт саклый. *(Ат, сыер, эт)*

Сакаллы килеш туа, берәү дә гаҗәпләнми. *(Кәҗә)*

ӨЧЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Дусларым

[у], [ү] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигъри юлларны бер тапкыр укып чыга.** Икенче тапкыр укыганда балалар тәрбияче артыннан кабатлыйлар һәм туп белән төрле хәрәкәтләр ясыйлар.

***Туп-туп тубыбыз***

Туп-туп тубыбыз,
Син – безнең матурыбыз,
Тишмәбез дә югалтмабыз,
Оста тота кулыбыз. (*Тупны балалар бер-берсенә бирә*)

Рөстәм, сиңа да бирәбез,
Әйдә, уйныйбыз бергә,
Кирәк аны, чөеп-чөеп,
Тотып ала белергә. (*Балалар бер-берсенә тупны чөеп-чөеп ыргыталар*)
Туп сикерә, син дә сикер,
Тыпыр-тыпыр тыпырда,
Дуслар белән уйна бергә,
Читтә генә утырма. (*Балалар бер урында сикерәләр*)

*Әминә Бикчәнтәева*

Тәрбияче балалардан кайсы сүзләрдә [у] авазы ишетелүен сорый. *Туп, матур, кул, уйныйбыз, дуслар, утырма* сүзләрен бергә кабатлыйлар.

**2. Тәрбияче әкиятне укый.** Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

***Торна белән Төлке***

Төлке Торна белән дуслашкан һәм аны кунакка чакырган. «Кил, дустым, кил, кадерлем!» – дигән.

Торна кунакка килгән. Төлке ботка пешергән. Аны күп итеп сай тәлинкәгә салган. «Аша, дустым, аша!» – дигән.

Торна борыны белән тәлинкәне тук-тук чукыган. Авызына ботка эләкмәгән. Ә Төлке ботканы үзе ашап бетергән.

– Иртәгә үзең миңа кил, – дигән Торна.

Икенче көнне Төлке Торнага кунакка килгән. Торна озын чүлмәккә борчак салган да: «Аша, дустым, аша!» – дигән. Төлке чүлмәктән бернәрсә дә ала алмый икән. Ә Торна озын борыны белән чүлмәктән борчакны чүпли икән. Ул борчакны ашап та бетергән.

Шуннан бирле Төлке белән Торнаның дуслыгы да беткән, ди.

1) Синең дустың кем?
2) Дуслар белән бергә уйнау күңеллеме?
3) Төлке нинди дус?
4) Төлке белән Торнаның дуслыгы ни өчен беткән?

**3. [у], [ү] авазлары кергән сүзләр белән эш.**
1) Тәрбияче сүзләрне укый. Аларның кайсысында [у] авазы, кайсыларында [ү] авазы кулланылуын сорый.

Кунак, күп, дус, тук-тук, үзе, үзең, чукыган, чүлмәк

2) Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә һәм балалардан җөмләләрне кабатлата.

*Тәрбияче туп рәсеме күрсәтә.*

Гүзәл белән Алсу туп белән уйный.

*Тәрбияче Торна, чүлмәк, борчак рәсемнәре күрсәтә.*

Торна чүлмәктән борчак ашый.

## ДҮРТЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Яраткан шөгылем

[о], [ө] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Балалар түгәрәккә тезелеп басалар, тәрбияче – уртада.** Ул шигырь юлларын бер тапкыр укып чыга. Икенче тапкыр укыганда, балалар да аның артыннан кабатлыйлар һәм тиешле хәрәкәтләр ясыйлар. Тәрбияче [ө] авазының дөрес әйтелүенә игътибар итә.

***Бик арыдык***

| | |
|---|---|
| Бакчада саф һава суладык, | *тирән итеп сулыйлар,* |
| Бик арыдык! | *туктап, ял итәләр* |
| Шакмаклар, тартмалар, өйгәләп, | *кирпеч өю хәрәкәтләре ясыйлар* |

Өйләр төзедек, бергәләп. *иелеп, кулларын аска*
Бик арыдык! *төшереп селкиләр*

Сорауларга җавап бирәләр.

1) Өйләрне кемнәр төзи?
2) Өйләрне нәрсәдән төзиләр?

**2. Тәрбияче әкиятне бер тапкыр укый.** Икенче тапкыр берәр җөмләләп укый, балалардан [о], [ө] авазлары кергән сүзләрне әйттереп бара. Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

***Төлке белән Каз***

Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:
– Каз, мин сине ашыйм! – дигән.
– Мин риза, Төлке. Тик мин бер биим әле, – дигән Каз.
– Әйдә, бие, – дигән Төлке. – Ашарга өлгерермен әле.
Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган.
Төлке:
– Әй оста биисең, Каз! – дип көлә икән.
Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очып киткән. Төлке авызын ачып калган.

1) Казга нинди шөгыле Төлкедән качарга булыша?
2) Син бии беләсеңме?
3) Син җырлый беләсеңме?
4) Син рәсем ясарга яратасыңмы?
4) Син нәрсә эшләргә яратасың?

**3. Тәрбияче рәсемнәр ярдәмендә җөмләләрне кабатлата.**

*Тәрбияче каз рәсеме күрсәтә.*
Каз оста бии.

*Тәрбияче төлке рәсеме күрсәтә.*
Төлке бии белми.

*Тәрбияче торна рәсеме күрсәтә.*
Торна да оста бии.

*Тәрбияче торна, каз, болыт рәсеме күрсәтә.*
Торна белән каз болытлар янында оча.

*Тәрбияче төлке, болыт рәсеме күрсәтә.*
Төлке болытлар янында оча алмый.

БИШЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Әкият, шигырь геройлары

[ō], [э̄] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне укый.** Сораулар ярдәмендә шигырь, шагыйрь, герой төшенчәләрен аерырга өйрәтә. Герой сүзендә [ō], [э̄] авазларын дөрес әйтүгә игътибар итә.

***Куян***

Борын-борын заманда
Яшәгән, ди, бер куян.
Ул шундый бер тиктормас,
Кызыксынучан булган.

Җәнлекләрнең сөйләшкәнен
Бик тыңларга яраткан.
Аларның сүзен, серләрен
Тирә-юньгә тараткан.

Сүзләр тыңлап йөри торгач,
Колаклары зур үскән.
Күреп озын колакларын,
Куян куркуга төшкән.

Шуннан бирле куянкай
Куркак булып калган, ди.
Исеме дә аның хәзер
«Озынколак» булган, ди.

*Гүзәл Галләмова*

1) Мин сезгә нәрсә укыдым?
а) шигырь ә) әкият

2) Шигырьне кем яза?
а) язучы ә) шагыйрь

3) Бу шигырьнең герое кем?
а) куян ә) бүре

4) Бу шигырьнең герое нинди?
*Балалар үз вариантларын әйтәләр.*

**2. Тәрбияче шигырьне укый. Авторын әйтә.** Сорауларга бергәләп җавап бирәләр.

### *Сәгать*

Сәгать суга: «даң, даң!..»
Хәбәр бирә таңнан:
Бакчага барырга
Унбиш минут калган.

Сикереп торды Марат,
Күрә – эшләр харап.
Тагын соңга калган,
Шул йокыга карап.

Сәгать йөри: «келт, келт!..»
– Тиз бакчага кит, кит!..
Марат аңа дәшә:
– Тукта, мине көт, көт!..

Сәгать җырлый: «диң, диң!..»
– Мин бит туктый белмим.
Моннан ары: «зиң, зиң!»
Миңа карап йөр син!..

*Муса Җәлил*

1) Шигырьнең герое кем исемле?
2) Ул ни өчен бакчага соңга калган?
3) Сәгать безгә ни өчен кирәк?

АЛТЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

## Әкият, шигырь геройлары

[ы], [ы̄] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче әкияттән өзекне укый.**

### *Җиде тычкан футбол уйный*

Җиде тычкан яшәгән ди. Тычканнар Чичибәк, Чичисылу, Чичибикә, Чичифән, Чичизат, Чичигөл, Чичиморат исемле булган.

Чичиморат та йокыдан уянган. Туганнары торганнар, иртәнге ашны да ашаганнар. Энеләренә зур гына кисәк сыр калдырганнар. Чичиморат ашаган да кунак бүлмәсенә чыккан. Ә туганнар нәрсә турындадыр сөйләшәләр, ди. Чичизат бер тишек чикләвек тапкан икән.

– Әйдәгез, футбол уйныйбыз! – дип чыелдаган Чичифән. – Мин уенның кагыйдәләрен беләм.

– Мин капкачы булам! – дигән Чичиморат.

– Футболны ике команда уйнарга тиеш, – дигән Чичифән.

– Сеңелкәшләр энекәшләр командасына каршы уйный. Мин – капкачы! – дигән Чичигөл.

Чичиморат аның каршы ягына урнашкан. Чичифән белән Чичисылу – һөҗүмчеләр. Чичибикә һәм Чичизат – сакчылар. Чичибәк судья булган. Шулай итеп тычканнар футбол уйный башлаганнар. Тычканнар тавышын ишетеп, песи тишектән идән астына башын тыккан.

Тычканнар озын мыеклы песине күреп курыкканнар, икенче бүлмәгә кереп качканнар.

*Лилия Фәрхетдиновадан*

Тәрбияче *йокы, сыр* сүзләрен әйтә, балалардан да әйттерә. Ни өчен ы хәрефенең төрлечә әйтелүе турында сорый.

**2. Тәрбияче татар сүзләрендә [ы], рус теленнән кергән сүзләрдә [ы̄] авазы ишетелүен әйтә.** Җөмләләр ярдәмендә бу авазларны дөрес әйтергә өйрәтә.

*Тәрбияче тычкан рәсеме күрсәтә.*

Тычкан йокыдан торды.

*Тәрбияче сыр рәсеме күрсәтә.*

Туганнары аңа сыр калдыра.

*Тәрбияче футбол уены рәсеме күрсәтә.*

Тычкан балалары футбол уйный.

**3. Тәрбияче сүзләрне укый.** Балалар кайсы сүздә [ы], кайсысында [ы̄] авазы ишетелүен әйтәләр, сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлыйлар.

Тычкан, капкачы, сыр, йокы, мыек

**4. Тәрбияче балаларга сораулар бирә.**

1) «Җиде тычкан футбол уйный» шигырьме, әкиятме?
2) Тычканнар нинди уен уйный.
3) Тычканнар нәрсәдән куркалар?

# ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ

ҖИДЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Бакчада

[н], [ң] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укып чыга.** Балалар белән бергәләп сорауларга җавап бирәләр.

***Көз һәм балалар җыры***

– Көз, Көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
– Кәрзинемдә кыярлар,
Помидор һәм алмалар.
– Көз, Көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
– Кәрзинемдә яңгырлар,
Җылы, суык көннәр бар.
– Көз, Көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
– Кәрзинемдә сары, кызыл,
Алтын, матур төсләр бар.

*Г. Гәрәева*

1) Җиләк-җимеш кайчан өлгерә?
2) Көз кайсы ел фасылы артыннан килә?
3) Сезнең бакчагыз бармы?
4) Анда нәрсәләр үсә? (кыяр, чөге**н**дер, суга**н**, помидор, кишер, шалка**н**, бәрә**ң**ге, ...)
5) Бакчада нинди җиләк-җимеш үсә?
6) Син нәрсә яратасың?
7) Җиләк яратасыңмы?
8) Нинди җиләк яратасың? (кызыл, сары, яшел)

**2. Тәрбияче *кәрзинеңдә – кәрзинемдә, көннәр – яңгырлар* сүзләрен әйтә, балалар аның артыннан кабатлыйлар.** Ул балалардан кайсы сүздә [н] авазы, ә кайсы сүздә [ң] авазы ишетелүен сорый: *яңгырлар* сүзендә – [ң] авазы, *кәрзинемдә, көннәр* сүзләрендә [н] авазы, *кәрзинеңдә,* сүзендә [н], [ң] авазлары ишетелә.

**3. Тәрбияче балаларга кәрзин күрсәтә һәм атамаларында н, ң хәрефләре кергән ике яшелчәнең рәсемен кәрзингә сала:**

шалкан – сары төстә, түгәрәк (йомры), тамыры тычкан койрыгына охшаган яшелчә;
бәрәңге – чәчәкләре ак яки зәңгәрсу төстәге яшелчә, эре яки вак була.
Тәрбияче балалардан кайсы сүздә [н] авазы, ә кайсы сүздә [ң] авазы ишетелүен сорый. Ул сүзләрне бергәләп кабатлыйлар.

**4. Тәрбияче табышмаклар әйтә һәм җавапларны кат-кат кабатлата.**

Җәйге эссе көннәрдә
Мине сагынып көтәләр.
Мин аз гына күренсәм,
Качып-посып бетәләр. *(Яңгыр)*

Үзе йомры – ай түгел,
Төсе сары – май түгел,
Койрыклы – тычкан түгел. *(Шалкан)*

Җир астында җиз бүкән,
Һәркөн ашыйсың, иркәм. *(Бәрәңге)*

**5. Тәрбияче балалардан бәрәңгедән әзерләнгән кайсы ризыкларны яратуларын сорый.** Ул *өчпочмак, бәлеш, кыстыбый* рәсемнәрен күрсәтә. Бу сүзләрдә [н], [ң] авазларының бармы-юкмы икәнлеген сорый.

**6. Тәрбияче балалардан н, ң хәрефләре булган сүзләрне кертеп (шалкан, чөгендер, суган, бәрәңге рәсемнәрен күрсәтә), җөмләләр төзетә.**

1) Бакчада нәрсәләр үсә?

– Бакчада **шалкан** үсә. – Бакчада **чөгендер** үсә. Бакчада **суган** үсә. Бакчада **бәрәңге** үсә. Бакчада ... .

2) **«Кәрзинеңдә ниләр бар?» уены.**

Көз, Көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
– Кәрзинемдә **кызыл алмалар** бар. – Кәрзинемдә салкын яңгырлар бар. Кәрзинемдә җылы көннәр бар. – Кәрзинемдә ... .

СИГЕЗЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Урманда

*-лар/-ләр, -нар/-нәр кушымчаларын дөрес куллану*

**1. Тәрбияче шигырьне укып чыга.** Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

***Урманда***

«Җиләк җыям, җиләк җыям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк микән?»

Марс килгән урманга
Кура җиләк җыярга.
Җыйсын әле күп итеп,
Безгә җитәрлек итеп.

«Җиләк җыям, җиләк җыям
Әбиемә бүләк», – дип.
Әби тәмләп чәй эчәр,
«Улым җыйган җиләк», – дип.

*Клара Булатовадан*

1) Нәрсә ул урман? Синең анда булганың бармы?
2) Урманда нәрсәләр үсә? (агачлар, куаклар, чәчәкләр, җиләкләр...)
3) Урманда нәрсәләр яши? (аюлар, бүреләр, төлкеләр, керпеләр, ...)
4) «Әбиемә бүләк» дип, кем җиләк җыя?
5) Марс урманга ни өчен бара?
6) Әби җиләктән кайнатма ясыймы?

**2. Тәрбияче исемнәрне берлек һәм күплек саннарда укый.** Башта бер предмет рәсемен, аннан соң берничә предмет ясалган рәсемне күрсәтә. Күплек санны белдерү өчен, сүзләргә *-лар/-ләр*, (м, н, ң) авазларына беткән сүзләргә *-нар/-нәр* кушымчалары ялгануын әйтә: *аю – бер аю* (аю берәү генә була), *аюлар – ике аю, өч аю* (аюлар күп була); *бүләк – бер бүләк* (бүләк берәү генә була), *бүләкләр – ике бүләк, өч бүләк* (бүләкләр күп була); ***урман*** ([н] авазына беткән) – *урма**ннар***, *борын* **–** *боры**ннар***.

**3. -лар/-ләр, -нар/-нәр кушымчалары кергән сүзләр белән эш.** Тәрбияче балалардан сүзләрне берлектә, күплектә әйттерә.

| | Күплектә | |
|---|---|---|
| **Сүзләр** | **-ләр, -ләр** | **-нар, -нәр** |
| җиләк | | |
| бүләк | | |
| әни | | |
| урма**н** | | |
| аю | | |
| бүре | | |
| боры**н** | | |

**4. Тәрбияче «Аю-бүре» уенын уйнарга тәкъдим итә.**

Балаларның берсе, аю яки бүре булып, берәр җирдә посып тора. Башкалары урманга «җиләк җыярга» китәләр. Тәрбияче балалардан сораша:

– Дуслар, кая барасыз?
– Кара урманга барабыз.
– Кара урманда нишлисез?
– Күп җиләкләр җыябыз.
– Аны кемгә бирәсез?
– Аны әбигә бирәбез.
– Бүре килсә нишлисез?
– Урман буйлап чабабыз.

Бүре яшеренгән җиреннән сикереп чыга да аларны куа башлый. Кемне тотса, шул бүре була.

**5. -лар/-ләр, -нар/-нәр кушымчалары кергән сүзләрне кабатлату максаты белән, тәрбияче балалар белән бергәләп җөмләләрне тулыландыра.**

Урманда җиләк___ күп.
Урманда аю___, бүре___ яши.
Урманда агач___, гөмбә___, чәчәк___ үсә.
Безнең илдә урман___ күп.

ТУГЫЗЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

**Кыш**

[к], [к] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне бер тапкыр укып чыга.**

### *Кыш килде*

Ап-ак тун киеп, кыш килде,
Яфрак-яфрак кар ява.
Без дә кидек җылы туннар,
Куркытмый салкын һава.

Чормадан сикереп төште
Чаңгылар һәм чаналар.
Ак мамыктай ап-ак кышны
Сагынып көткән алар.

Сөенәбез, шатланабыз,
Күңелле үтә кышлар.
Чаңгы, чана, тимераяк –
Безнең иң якын дуслар.

*Гөлшат Зәйнашева*

**Чорма** – чердак

1) Кайсы ел фасылы ап-ак тун киеп килә?
2) Яфрак-яфрак кар яуганны күргәнең бармы?
3) Тимераякта шуарга яратасыңмы?
4) Сезнең янда шугалак бармы?
5) Яз көне чаңгы, чана һәм тимераякны кайда саклыйсың?
6) Ни өчен син кышны яратасың?

**2. Укытучы шигырьнең беренче куплетын кабат укый.** Икешәр юллап та укый, балалардан кайсы сүзләрдә [к] авазы, ә кайсы сүзләрдә [қ] авазы ишетелүен сорый:

[к] авазы булган сүзләр: *киеп, килде, кидек, сикереп, көткән, күңелле;*
[қ] авазы булган сүзләр: *ап-ак, кыш, яфрак, кар, куркытмый, салкын, мамыктай, кышны, кышлар, тимераяк, якын.*

**3. «Кем тизрәк?» уены.** Тәрбияче балалар белән Г. Зәйнашеваның «Кыш килде» шигырендә [к], [қ] авазлары булган сүзләрне искә төшерә: *кыш, кар, тимераяк, ак*, ... .

**4. «Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены.**

Кышын тауда шуалар, җәен җыеп куялар. Нәрсә ул? *(Чана)*

Биш агайга бер күлмәк. *(Бияләй)*

Җир өстендә ак мамык. *(Кар)*

Үзе су, үзе каты. *(Боз)*

Аягы юк, кулы юк, үзе тәрәзәгә рәсем ясый. *(Суык)*

**5. «Мин башлыйм, син дәвам ит!» уены.**

Кы, кы – кыш, ка, ка – кар, ма, ма-мык, яф, яф-рак, кил, кил-де, ... .

УНЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

**Яз**

[э] *авазын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне бер тапкыр укып чыга, балаларга кайсы сүзләрдә [э] авазы барлыгына игътибар итәргә куша.**

***Бу кайсы вакыт?***

Боз һәм кар **эреде**,
Сулар **йөгерде;**
Елап елгалар,
Яшьләр **түгелде**.

Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?
Йә, **әйтеп** кара.
*Габдулла Тукай*

1) Бу кайсы вакыт? Ул кайсы ел фасылыннан соң килә?
2) Боз һәм кар кайчан эри башлый?
3) Кайчан «көннәр озыная, төннәр кыскара»?
4) Әлеге шигырьдә язның беренче билгеләре бармы?
5) Яз көне кайсы кошлар беренче булып кайталар?

**2. Татар һәм рус телләрендә [э] авазы булган сүзләрне чагыштыру.**

Татар телендә: эреде [эрэдэ], түгелде [түгэлдэ], әйтеп [әйтэп] сүзләрендә [э] авазы кыска итеп әйтелә.

Рус телендә: генерал [гэ̄нэ̄рал], герой [гэ̄рой] сүзләрендә [э̄] авазы озын итеп әйтелә.

**3. Эндәшләр, әйтешләрдә [э] авазы булган сүзләрне тап.**

1) Карга әйтә: «Кар, кар!
Тиздән **эреп бетәр** кар,
Канатымда хатым бар,
Буең җитсә, тартып ал».

2) Там, там, тамчы, там,
Тамганыңны яратам.

Тамган тамчыларга карап,
Мин **көлергә** яратам.

3) Каенда – карга,
Имәндә – чыпчык,
Юкәдә – **күке**,
Җирдә – елан,
Һавада – кош,
Бар син оч!

**4. «Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены.**

Агач башында йорты,
Эчендә яши җырчы. *(Сыерчык)*

Борынсыз чыпчык боз тишә. *(Тамчы)*

Ут та түгел, ук та түгел,
Күзгә төшә, карны кисә. *(Кояш нуры)*

УНБЕРЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Җәй**

[ж] *авазын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне бер тапкыр укып чыга.**

***Җиләктә***

Әнисе белән Гөлия
Бүген җиләккә барды.
Чиләгенең иң матурын –
Чәчәк төшкәнен алды.

Үзе эре, үзе пешкән,
Җиләге дә җиләге!
Күпме генә вакыт узды,
Инде тулды чиләге.

Аннары җыйды тәлгәшләп,
Сыйлар өчен энесен.
«Минем уңган кызым!» – диеп,
И мактады әнисе.

*(тәлгәшле җиләк рәсеме күрсәтелә)*

*Гүзәл Галләмова*

1) Җиләккә кемнәр бара?
2) Җиләкне кәрзингә җыялармы?
3) Гөлия җиләкне чеме белән (тәлгәшләп) җыямы?
4) Ул җиләк белән кемне сыйларга тели?
5) Әнисе кызны мактыймы? Нәрсә ди?
6) Сине әти-әниең еш мактыймы? Нинди тәмле сүзләр әйтеп мактыйлар?

**2. Тәрбияче балаларга шигырьдән [ж] авазы булган сүзләрне табарга куша.**
[ж] авазы кергән сүзләр: *җиләккә, җиләге, җыйды*

**3. [ж] авазының парын табыгыз**: [ж] – [ч] – *җиләк – чиләк.*

**4.** Тәрбияче **җ хәрефеннән башланган сүзләр әйтергә куша:** *җир, җыр, җомга*, *Җәмилә, Җәмил, җан, ... .*

**5. «Кәрзинеңдәниләр бар?» уены.**

«Җәй, җәй, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?»
– Кәрзинемдә җылы кояш,
Тәмле җиләк, гөлләр бар.
Җәй, җәй, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
– Кәрзинемдә карлыганнар,
Чияләр, сливалар.
Җәй, җәй, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
– ... .

**6. Җәйнең билгеләрен әйтегез.** Җәй ел фасылына кайсы айлар керә?

Июнь
Сайрый-сайрый кошлар оча,
Зәңгәр күкләрне иңләп.

Июль
Җәйнең иң кызу чаклары,
Кызаралар җиләкләр.
Күләгәгә яшеренгән
Җәнлекләр һәм бөҗәкләр.

Август
Бакчаларда җиләк-җимеш,
Яшелчәләр өлгерә.

Барысы үзенә дәшә,
Син җыеп өлгер генә.

*Гүзәл Галләмова*

УНИКЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Көз**

*[г], [ғ] авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигъри юлларны бер тапкыр укып чыга.**

***Көз***

Үтте-китте матур җәйләр,
Көзләр килеп җиттеләр.
Ак каенның яфраклары
**Саргаешып** киптеләр.

*Кави Нәҗми*

***Бу кайчак була?***

Кырлар буш кала,
**Яңгырлар** ява;
Җирләр дымлана,
– Бу кайчак була?

*Габдулла Тукай*

**Көзгә** таба бакчада
Яшелчәләр җитешә.
– Кайсыбыз иң яхшысы? –
Дип, алар бәхәсләшә.

*Вәсимә Хәйруллина*

**2. Тәрбияче балаларга [г], [ғ] авазлары булган сүзләрне табарга куша:**

Нечкә [г] авазы кергән сүз: *көзгә.*
Калын [ғ] авазы кергән сүзләр: *саргаешып, яңгырлар.*

**3. [г], [ғ] авазлары кергән сүзләрне икегә аерып әйт.**

гөл, яңгыр, елга, белгән, Гөлүсә, Гамир.

**4. Тәрбияче тел көрмәкләндергечне укый һәм [г] авазы кергән сүзне таптыра.**

Ваттым мичкә, яктым мичкә,
Бер мичкәне бер кичкә.
Атна буе **эшләгәнем**,
Җитте бары бер кичкә.

**5. Тәрбияче алдавыч әкиятне укый һәм [г], [ғ] авазлары кергән сүзләрне табарга куша.**

Борын-борын заманда
**Булган**, ди, бер мичкә.
Ярар инде, **сораган** әкиятеңне
Сөйләрмен **иртәгә** кичкә.

**6. «Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены.**

Турыйсың-турыйсың,
Тураганда елыйсың. *(Суган)*

Озынча, түтәлдә үсә, яшел төстә, эчендә
бик күп орлыклары бар. *(Кыяр)*

Язын дөньяга килә,
Көзен саргаеп үлә. *(Яфрак)*

**7. Ел фасылларын кабатлау.** Тәрбияче шигырьне укый, *җәй, көз, кыш, яз* – ел фасылларын билгеләтә.

1.
Елгалар ярына кайтты.
Ташулар басылдылар.
Кояшка карап, елмаеп,
Бөреләр ачылдылар. ( ______ )

2.
Печән үсте, җиләк пеште,
Өзелеп, җиргә төште.
Кош баласы, җиләк кабып,
Үрелеп, сулар эчте. ( ______ )

3.
Сайрар кошлар очып китте,
Болытлар яшен түкте.
Таң алдыннан чәчәкләрне
Кыраулар төшеп үпте. ( ______ )

4.
Урамнарга ак мамыктан
Юрган тегә бураннар.
Ай-һай җылы юрган, диеп
Сөенәләр урамнар. ( ______ )

*Г. Шаһиев*

## ТУГАН ИЛЕМ

УНӨЧЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Шәһәрдә**

[h] *авазын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укып чыга.** Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

***Каргалар шәһәре***

Язын ерак-ераклардан
Очып килде каргалар,
Тал башына зур бер шәһәр
Төзеп куйдылар алар.

Берәүләре йөк ташыйлар –
Чыбык-чабык, йон, салам,
Калганнары төзүчедәй
Оста итеп йорт сала.

Урамнары шундый кызык –
Ботак саен бер урам.
Бер карга хәтта үзенә
Ике катлы йорт корган.

...Озакламый һәрбер йортта
Нәни каргалар туды.
Тиз арада бар шәһәргә
Карга баласы тулды.

Шунда гына төшендек без,
Шаккатып калдык мәгәр –
Балалар бакчасы итеп
Төзелгән бит бу шәһәр.

*Гәрәй Рәхим*

1) Шигырьнең авторы кем?
(Тәрбияче балаларның Рәхим сүзен дөрес әйтүенә игътибар итә)

2) Шигырьнең геройлары нәрсәләр?

3) Каргалар нәрсә төзи? (Тәрбияче балаларның шәһәр сүзен дөрес әйтүенә игътибар итә, хаталарны төзәтә)

4) Каргалар шәһәре нинди? (Һәр бала бер җөмлә әйтә)

5) Каргалар нинди һөнәрләр белә?

**2. Тәрбияче [h] авазы кергән сүзләрне әйтә, балалар аның артыннан кабатлыйлар.**

Шәһәр, һәрбер, һәм, һава, һәркем, һөнәр

**3. Тәрбияче каргалар шәһәре белән кешеләр яши торган шәһәрләрне чагыштырырга куша.** Балаларны ике төркемгә бүлә. Төркемнәр чиратлап җөмләләр әйтә. Бер төркем каргалар шәһәре турында, икенчесе кешеләр шәһәре турында.

| Каргалар шәһәре | Кешеләр шәһәре |
|---|---|
| | |

**4. Тәрбияче табышмаклар әйтә. Балалар җавапны әйткәч, рәсемен күрсәтә.**

Шәһәрләр – йортсыз,
Диңгезләр – сусыз. *(Карта)*

Үзе шушында, үзе беленми;
Тынга беленә, күзгә күренми. *(Һава)*

Чабалар кызыл йортлар.
Туры һәм коры юлдан. *(Трамвай)*

Әйтә безгә: шәһәрдә юл йөргәндә
Сак булырга онытма! *(Светофор)*

УНДҮРТЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Авылда

[в], [w] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче текстны укый.** Балалар белән сорауларга җавап бирәләр.

### *Велосипедлы Мөнир*

Мөниргә әтисе магазиннан яңа велосипед сатып алды. Мөнир, велосипедын алып, урамга чыкты. Аның янына дус малайлары килде.

– Мөнир, мин дә йөрим әле? – диде Илдус.

Мөнир велосипедын бик кызганды. Ул велосипедта йөри белми иде.

– Ярар, син генә йөреп карарсың, – диде ул Илдуска. – Мин утыргач, син велосипедны тотарсың... Әнә теге чыршы янына җиткәч, мин төшәрмен дә син утырырсың.

Велосипед башта әле бер якка, әле икенче якка ауды. Әгәр Илдус тотмаган булса, Мөнир егылыр иде.

Тиздән иптәшләре дә, авыл да артта калды. Алар чыршы янына да якынлаштылар.

– Тукта инде, Мөнир... – диде Илдус.

Мөнир туктамады. Илдус Мөнирнең велосипедын ычкындырды да, авылга таба йөгерде.

Велосипедның алгы тәгәрмәче читкә кереп китте. Мөнир велосипеды белән юл читендәге чокырга егылды.

*Нурихан Фәттах*

1. Мөниргә велосипедны кем ала?
а) әнисе ә) әтисе
2. Мөнир кайда яши?
а) авылда ә) шәһәрдә
3. Мөнир Илдуска велосипедын кайсы агач янында бирәм ди?
а) чыршы ә) каен
4. Мөнир Илдуска велосипедын бирәме?
а) әйе ә) юк

**2. Тәрбияче [в], [w] авазлары кергән сүзләрне әйтә, балалар аның артыннан кабатлыйлар.**

Велосипед, авыл, вакыт, савыт, вертолет, тавык, һава, вагон, трамвай.

## УНБИШЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Хайваннар дөньясы

[х] *авазын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне кычкырып укый.** Бергәләп сорауларга җавап бирәләр.

***Урманда***

Бирeдә кошлар, җәнлекләр
Читлеккә ябылмаган.
Урманы да койма белән
Уратып алынмаган.

Ул куяннар, ул пошилар,
Ул керпеләр, тилгәннәр
Казандагы зоопарктан,
Ахры, качып килгәннәр.

Алар безне күргәчтен,
Без урманга кергәчтен,
Тизрәк качып китәләр,
Тизрәк очып китәләр.

Юкса без ул җәнлекләргә,
Кошларга тиябезме?
Алар бит матурлый гына
Әйләнә-тирәбезне.

Без бит яратабыз гына
Аларны – белдегезме?!
«Курыкмагыз!» – дияр идем,
Белсәләр телебезне.

Белмиләр шул. Алар шулай
Гел качарга торалар.
Зоопаркка ябарлар, дип,
Куркып качадыр алар.

*Роберт Миңнуллин*

1) Җәнлекләрне икенче төрле ничек атыйлар? (Тәрбияче балаларның *хайваннар* сүзендәге [х] авазын дөрес әйтүенә игътибар итә)
2) Урманда, тауларда яши торган хайваннар ничек атала? (кыргый хайваннар)
3) Кешеләр янында яши торган хайваннар ничек атала? (йорт хайваннары)
4) Хайваннарга, кошларга тияргә ярыймы?

QR-код
яки https://youtu.be/Lu8zmqwuo7I сылтамасы аша узып, йорт хайваннары турындагы язманы карарга була.

**2. Тәрбияче хайван атамаларын әйтә, рәсемнәрен күрсәтә.** Балалар кыргый хайван атамасын ишеткәч, торып басарга тиеш була. Йорт хайваны атамасын ишеткәндә, утырып торалар.

куян, кәҗә, поши, керпе, ат, сарык, аю, арыслан, сыер, песи, бүре, эт, төлке, тиен, үгез, юлбарыс.

**3. Тәрбияче табышмаклар әйтә.** Балалар җавап биргәч, рәсемнәрен күрсәтә.

Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак. *(Куян)*

Бер нәрсә тегә белми,
Энәләр тагып йөри. *(Керпе)*

Җәен урманга патша,
Кышын кардан да аста. *(Аю)*

Нечкә билле, көлтә койрыклы. *(Төлке)*

Кош түгел – оча,
Ябалактан курка.
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны яңгырата. *(Тиен)*

Сорыдыр төсе,
Үткендер теше.
Урманда йөри,
Бозаулар эзли. *(Бүре)*

**4. Тәрбияче [х] яки [һ] авазы кергән сүз әйтеп, бер балага тупны бирә.** Бала сүзне кабатлый. [х] авазы кергән сүз булса, тупны башка балага, [һ] авазы кергән булса, кабат тәрбиячегә бирә.

Куллану өчен сүзләр: хайван, һава, шәһәр, хат, һөнәр, хезмәт һәм башкалар.

## УНАЛТЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

### Кошлар

[к], [қ] *авазларын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигырьне укый.** Балалар белән бергә сорауларга җавап бирәләр.

***Үрдәк зары***

Үрдәк кайта көчкә атлап,
Үрдәк әйтә: «Бак-бак-бак,
Күлдә балык вак-вак-вак,
Ач калмадым чак-чак-чак.
Ә эресе кая киткән?

Нигә күлнең суы кипкән?
Җавап тап-тап-тап!».
*Йолдыз*

1) Үрдәк күлдә нәрсәләр ашый?
2) Үрдәк йорт кошымы?
3) Тагын нинди йорт кошларын беләсең?
4) Нинди кыргый кошлар беләсең?
2) Күлнең суы ни өчен кипкән икән?

**2. Тәрбияче чишмәләрне, елгаларны, күлләрне сакларга, сулыкларны, яр буйларын чистартырга кирәклеге турында әңгәмә үткәрә.**

**3. Тәрбияче шигырьдән [к], [қ] авазлары кергән сүзләрне сайлап алып укый.** Балалар аның артыннан кабатлыйлар. Авазларны әйтүдә хаталар булса, тәрбияче төзәтә.

Үрдәк, кайта, көчкә, бак-бак-бак, күлдә, балык, вак-вак-вак, калмадым, чак-чак-чак, кая киткән, күлнең, кипкән

**4. Тәрбияче «Кайсы артык» уенын уйната.**
Тәрбияче өч кош атамасын әйтә. Балалар ул атамаларның кайсысы артык булуын һәм ни өчен артык булуын әйтергә тиеш.

1) тукран, кәккүк, тавык
2) ябалак, әтәч, үрдәк
3) ала карга, күркә, күгәрчен
4) чыпчык, сыерчык, каз

## УНҖИДЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Милләтләр дуслыгы

[и] *авазын дөрес әйтү*

**1. Тәрбияче шигъри юлларны ике тапкыр укып чыга.** Балалар белән сорауларга җавап бирәләр. Тәрбияче [и] авазының дөрес әйтелүенә игътибар итә.

Туган җирем! Матур таңнар
Иленә тиңлим аны.
Ул – минем Татарстаным,
Бар татарның Ватаны.

1) Туган җир нәрсә ул?
2) Син кайда яшисең?
3) Татарстанда татарлар гына яшиме?

Тәрбияче шигырьне берәр юллап укый. Балалар [и] авазы кергән сүзләрне әйтеп баралар.

**2. Тәрбияче текстны укый.**

Татарстан – татар халкының борынгы туган иле. Татарстанда якынча 4 миллион кеше яши. Татар халкы рус, чуаш, мари, башкорт, мордва, удмурд һәм башка халыклар белән дус яши.

Дус яшәргә кирәк җир йөзендә,
Дуслар кирәк һәрбер кешегә.
Дуслык булса яшәү дә күңелле,
Уңай була һәрбер эшең дә.

**3. «Әйлән-бәйлән уйныйбыз» җырын тыңлау.**

***Әйлән-бәйлән уйныйбыз***

*Р. Батулла сүзләре*
*Л. Батыр-Болгари музыкасы*

Әйлән-бәйлән уйныйбыз,
Матур җырлар җырлыйбыз.
Күңелле дуслар белән –
Бер дә уйнап туймыйбыз.

Кушымта:

Әйлән-бәйлән бергәләшеп уйныйбыз,
Әйдә, бергә кул тотышып биибез.

Әллә әйлән уйныйбыз,
Әллә сәйлән җыйныйбыз.
Әллә бәйлән уйныйбыз,
Әллә ләйсән җыйныйбыз.

Кушымта.

Уйныйбыз да уйныйбыз,
Өзмибез дә куймыйбыз.
Бик озак уйнасак та,
Бер дә уйнап туймыйбыз.

Кушымта.

УНСИГЕЗЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Милләтләр дуслыгы

*Өйрәнгән авазларның әйтелешен ныгыту*

**1. Тәрбияче шигырь юлларын укый.** Балалар белән сорауга җавап бирәләр. Тәрбияче балаларның барлык авазларны да дөрес әйтүенә игътибар итә. Хаталар булса, төзәтә. Төрле милләт вәкилләренең милли киемнәрен кигән курчаклар, рәсемнәр куллану сорала.

Без – бер илнең балалары,
Барыбыз да дуслар без.
Татарлар, удмурт, марилар,
Башкорт, мордва, руслар без.

1) Татарстан – ул төрле милләт халыклары яши торган зур йорт. Шундый зур йортта яшәсәләр дә, һәр халык үзенең туган телен онытмый. Үз телләрендә җырлар җырлыйлар, биюләрен бииләр, матур милли киемнәрен кадерләп саклыйлар.
Син нинди милләтләрне беләсең?

**2. Тәрбияче шигырьне укый.**

***Дуслык турында җыр***

Торсак та без төрле җирләрдә
Без яшибез дуслык илендә;
Сөйләшәбез төрле телләрдә,
Аңлашабыз дуслык телендә.

Үстергән дә безне чын дуслык,
Көч биргән дә безгә чын дуслык.
Дуслык булса, яшәр гомергә
Бөтен җир шарында тынычлык.

*Әхмәт Ерикәй*

QR-код
яки https://page.ligaudio.ru/mp3/%D0%B4%D1%83%D1%81%D0%BB%D1%8B%D0%BA (Дуслык турында җыр) сылтамасы аша узып, җырны тыңларга була.

**Тәрбияче балалар белән дуслык, тынычлык турында әңгәмә үткәрә.**

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

УНТУГЫЗЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

### Тылсымлы сүзләр

*Иҗек*

**1. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укый.**

***Тылсымлы сүзләр***

Иртән әни уята:
– Улым, хәерле иртә!
Шул тылсымлы сүз мине
Көн буе саклап йөртә.

Әби бакчага озата:
– Улым, – дип, – хәерле юл!
Әбием изге күңелле,
Гел хәерле була юл.

Бакчага баргач та
Телимен: «Хәерле көн!»
Әллә шуңа әйбәт кенә
Хәерле уза бу көн.

Кичен әти каршы ала:
– Хәерле кич, улым, – дип.
Бергәләшеп уйнаганда
Хәерле уза кич бик.

Гап-гади инде үзләре,
Катлаулы түгел һични.
Әмма хәерле иртәләр
Иртәне, көнне, кичне.

Мин шушындый сүзләр беләм.
Син дә беләсең микән?
Хәерле юл! Хәерле көн! –
Тылсымлы сүзләр икән.

*Йолдыз*

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Син нинди тылсымлы сүзләр беләсең?
2) Иртән йокыдан торгач, кайсы тылсымлы сүзләрне әйтәсең?

а) Хәерле иртә! ә) Хәерле көн! б) Хәерле кич!

3) Көндез әти-әниләргә, тәрбияче апаларга, бер-беребезгә кайсы тылсымлы сүзләрне әйтәбез:

а) Хәерле иртә! ә) Хәерле көн! б) Хәерле кич!

4) Кич белән кайсы тылсымлы сүзләрне әйтергә кирәк?

а) Хәерле иртә! ә) Хәерле көн! б) Хәерле кич!

**3. Тәрбияче әлеге тылсымлы сүзләрне иҗекләргә бүлеп әйттерә һәм һәр иҗектә бер сузык аваз барлыгын әйтә.**

Хәерле иртә! Хәерле көн! Хәерле кич!
Хә-ер-ле ир-тә, хә-ер-ле көн, хә-ер-ле кич.

ЕГЕРМЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Уен кораллары**

*Сүз*

**1. Тәрбияче балаларга шигырьне укый.**

***Курай***

Абый белән икәүләп
Ясадык без бер курай.
Уйнап җибәрсәк курай,
Кушылып сайрый тургай.

Сайрады да сайрады,
Яратты көебезне.
Болыннан өйгә кадәр
Озата килде безне.

*Рәшит Бәшәр*

**Курай** – дудка
**Тургай** – жаворонок

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Нинди музыка уен коралларын беләсең?
2) Нәрсә ул курай?
3) Курайда уйнаганны ишеткәнең бармы?

**3. Тәрбияче балаларга сүз белән җөмләне аерырга тәкъдим итә һәм җөмләнең сүзләрдән торганлыгын әйтә.**

курай (сүз)
Абый курайда уйный. (җөмлә)
гармун (сүз)
Ул гармунда уйный. (җөмлә)

тургай (сүз)
Тургай сайрады. (җөмлә)

**4. «Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены.** Тәрбияче, балалар табышмакның җавапларын әйткәч, уен коралларының рәсемнәрен күрсәтә.

Телләре бик күп булса да,
Һәркем аңлый, үз итә.
Елата да, җырлата да,
Кирәк икән – биетә. *(Гармун)*

Тартма өстендә таяк,
Таякта җиде җеп,
Җиде җептә җитмеш сайрар кош. *(Гитара)*

Эче буп-буш,
Тавышы дөньяга сыймый. *(Барабан)*

ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Татар халык әкияте**

*Капма-каршы мәгънәле сүзләр*

**1. Тәрбияче балаларга «Куркак юлдаш» дигән татар халык әкиятен укый.** Әкият буенча төшерелгән мультфильмны карарга тәкъдим итә.

Мультфильмны QR-код яки https://yandex.ru/video/preview/?text=куркак%20юлдаш%20экияте%20мультфильм&path=wizard&parent-reqid=1638876821664097-17002699676229345205-sas6-5252-3ed-sas-l7-balancer-8080-BAL-6045&wiz_type=vital&filmId=15900826013333304460 сылтамасы аша узып карарга була.

***Куркак юлдаш***

Ике дус урманга килгән. Боларның каршысына бер аю очраган. Моны күргәч, аларның берсе, бик куркып, агач башына менеп качкан. Икенчесе, үлгән булып, тиз генә җиргә сузылып яткан. Аю, бу юлда яткан кешенең янында әйләнә-әйләнә йөргән, башларын, аякларын иснәгән дә, ди, тимичә, үз юлына киткән, ди.

Аю киткәннән соң, әлеге кеше, агач башыннан төшеп, иптәшеннән сораган:

– Аю синең колагыңа шыпырт кына нәрсә әйтте? – дигән.

Бу кеше әйткән:

– Аю миңа моннан соң шушындый куркак кеше белән юлга чыкма, дип әйтте, – дигән.

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Ике дус кая барганнар?
2) Аларның каршысына нәрсә килеп чыккан?
3) Ике дусның берсе кая качкан?
4) Ни өчен икенчесе үлгән булып яткан?
5) Аю үлгән булып яткан дусның колагыңа шыпырт кына нәрсә әйткән?
6) Аю нәрсә әйтергә теләгән соң? – Бу куркак кеше белән бүтән юлга чыкма дигәнме?
7) Ул, агач башына менеп качып, дөрес эшләгәнме?
8) Куркак дус нинди була?

**3. Тәрбияче балаларга сүзләрне капма-каршы мәгънәләре белән парлап әйтергә тәкъдим итә.**

Батыр – ... . (куркак)
Дус – ... . (дошман)
Зур – ... . (кечкенә)
Аз – ... . (күп)
Ак – ... . (кара)

**4. Тәрбияче балаларга берәмләп сүзләрне укый һәм алар белән җөмләләр төзетә.**

Батыр, куркак, дус, ак

Үрнәк. *Минем батыр дустым бар.*

ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Татар исемнәре

*Җөмлә*

**1. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укый.**

***Исәнмесез, иптәшләр!***

Мин иртә белән
Өйләргә керәм,

Иптәшләремнең
Хәлләрен беләм:
Исәнме, Гүзәл,
Исәнме, Рүзәл!
Исәнме, Мәрьям!
Исәнме, Галләм!
Сезгә, дусларым,
Иртәнге сәлам!

Исәнме, Азат!
Саумы, Салават!
Авырмыйсызмы?
Хәят һәм Булат!
Исәнме, Иркә!
Сәлам, Мәликә!
Хәерле иртә!
Хәерле иртә!

*Хәләф Гарданов*

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Шигырьдә сүз нәрсә турында бара?
2) Герой иртә белән дусларының, иптәшләренең хәлләрен сорыймы?
3) Хәләф Гардановның «Исәнмесез, иптәшләр!» дигән шигырендә нинди кеше исемнәре очрый? *Тәрбияче шигырьне кабат укый.*

Кызлар исемнәре: Гүзәл, Мәрьям, Хәят, Иркә, Мәликә.

Малайлар исемнәре: Рүзәл, Галләм, Азат, Салават, Булат.

4) Бу исемнәр барысы да татар исемнәреме?
5) Гүзәл, Иркә, Азат исемнәре нәрсәне аңлата?

*Гүзәл (бик матур),* Иркә *(кадерле, иркә бала),* Азат *(ирекле).*

**3. Тәрбияче балаларга һәр кеше исеменең аңлатмасы барлыгын әйтә һәм аларны кайбер исемнәр белән таныштыра.**

Салават мактау җыры дигәнне аңлата.
Резеда – зәңгәр чәчәкле хуш исле гөл.
Рәис – председатель, җитәкче.
Мәрьям – кадерле.

**4. Тәрбияче балаларга биш татар исеме – кыз һәм малай исемнәре уйлап әйтергә тәкъдим итә.**

**5. Тәрбияче балалардан сүзләрдән җөмләләр төзетә һәм җөмләләрнең *нишли* дигән сүзгә тәмамлануын искәртә.**

Быел Мәрьям мәктәпкә бара. (нишли?)
Гүзәл рәсем ясый.
Мәликә гөлләргә су сибә.
Әминә песине ашата.

ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Сау бул, бакча! Исәнме, мәктәп!**

*Текст*

**1. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укый.**

***Әйбәт укучы булам***

Юк, булмас, дип көлмәгез,
Мактанчык та димәгез,
Мин мәктәпкә баргач та,
Әйбәт укучы булам.
Беләм дисезме кайдан
Бу хакта шулай алдан?
Чөнки мине быел ук
Тилмертәләр укытып.
Кич җитүгә көн саен
Кулга әлифба алам,
Кирәкле битне табам.
Башта укыйм хәрефләп,
Бик тырышып, бөртекләп.
Аннан укыйм иҗекләп,
Аннары укыйм сүзләп.
Башта укыйм әтигә,
Аннан укыйм әнигә,
Кабат укыйм әбигә,
Хәтта энем – бәбигә.
Безнең өйдә алты кеше,
Алты кат укыйм, димәк.
Әйбәт укучы булырга
Инде тагын ни кирәк?

*Йолдыз*

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Кем ул әйбәт укучы?

2) Әйбәт укучы әлифбаны ничә тапкыр укый?
3) Ул әлифбаны ничек итеп укый? (*бик тырышып, бөртекләп, иҗекләп, сүзләп*)
4) Башта әлифбаны кемгә укый? Ә аннары кемнәргә укый? Ничә кеше килеп чыга? (*әти, әни, әби, энесе-бәби, үзе*)
5) *Безнең өйдә алты кеше, Алты кат укыйм, димәк.* Алтынчысы кем булып чыга соң?

**3. Тәрбияче мәгънә ягыннан бер-берсенә бәйләнгән һәм берничә җөмләдән торган текст төзетә.**

Мин мәктәпкә укырга киттем. Менә 1 нче сентябрь дә җитте. Без бакча белән хушлаштык.

Текст: Без бакча белән хушлаштык. Менә 1 нче сентябрь дә җитте. Мин мәктәпкә укырга киттем.

**4. «Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены.** Табышмакның җавабын әйткән балага китап, буяу карандашлары яки авторучка бүләк ителә.

Юк аягы, юк күзе,
Сөйли, өйрәтә үзе.
Телгә аннан оста юк,
Аннан якын дус та юк. *(Китап)*

Бер ояда алты дус,
Алтысында алты төс.
Ләкин алар барысы да
Башкаралар бер үк эш. *(Буяу карандашлары)*

Үзе укый белмәсә дә,
Гомере буе яза. *(Авторучка)*

**5. Тәрбияче шигырьне укый.**

***Бакча белән хушлашу***

Олы бәйрәм бүген бездә,
Зурлар инде күбебез.
Бакча белән хушлашабыз,
Бүген соңгы көнебез.

Тик елыйсы килә минем,
Инде нихәл итәсе?
Бакчадан, дуслар яныннан
Бер дә килми китәсе.

Гел карап торырмын инде
Шушы бакча ягына.
Нигә укытмыйлар икән
Шушы бакчада гына?!

*Роберт Миңнуллин*

**6. Тәрбияче балалар белән «Бакчадан – мәктәпкә» темасына әңгәмә үткәрә.**

Файдалану өчен сораулар:
1) Синең бакчада дусларың бармы?
2) Бакчада син нәрсәләр эшләргә өйрәндең?
3) Бакчаны сагынырсыңмы? һ. б.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011. – 560 б.

Бикмуллина А.Ф. Йолдызлар шулай куша: балалар өчен хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 63 б.

Галиев Г. Аю агачлар белән... сөйләшә: Әкият / Как Медведь с деревьями... разговаривал: Сказка. – Казан: Мәгариф, 2003. – 40 б.

Галиев Ш. Шәвәли шуклыгы: балалар өчен шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 166 б.

Галләмова Г.Х. Җиләкле җәй: балалар өчен шигырьләр. – Казан: Рухият, 2012. – 40 б.

Зәйдулла Р.Р. Сабантуй сөлгесе: Балалар өчен хикәя. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 38 б.

Исхакова-Вамба Р.А. Уен җырлары. – Барда, 1994. – 112 б.

Йолдыз. Колаклы коймаклар: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 63 б.

Миннуллин Р.М. Безнең авыл зоопаркы: балалар өчен шигырьләр һәм җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1988. – 80 б.

Миннуллин Р.М. Күңелле тәнәфес: балалар өчен җырлар – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 173 б.

Сафин Ф.М. Әйдәгез, дуслашыйк!: шигырьләр, шигъри календарь. – Казан: Рухият, 2018. – 56 б.

Татар халык җырлары / Төз. Р. Шакирова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 238 б.

Туганнан алып мәктәпкәчә: Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы / Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендә. – Казан: ХӘТЕР, 2016. – 357 с.

Фәрхетдинова Л.Н. Өч алма. – Казан: Рухият, 2019. – 48 б.

ЭЧТӘЛЕК

Аңлатма язуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Беренче шөгыль. Безнең гаилә . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Икенче шөгыль. Безнең өй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Өченче шөгыль. Дусларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Дүртенче шөгыль. Яраткан шөгылем . . . . . . . . . . . . . 8
Бишенче шөгыль. Әкият, шигырь геройлары . . . . . . . 10
Алтынчы шөгыль. Әкият, шигырь геройлары . . . . . . . 11
Әйләнә-тирә дөнья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Җиденче шөгыль. Бакчада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Сигезенче шөгыль. Урманда . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Тугызынчы шөгыль. Кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Унынчы шөгыль. Яз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Унберенче шөгыль. Җәй. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Уникенче шөгыль. Көз. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Туган илем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Унөченче шөгыль. Шәһәрдә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Ундүртенче шөгыль. Авылда . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Унбишенче шөгыль. Хайваннар дөньясы . . . . . . . . . 25
Уналтынчы шөгыль. Кошлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Унҗиденче шөгыль. Милләтләр дуслыгы . . . . . . . . . 28
Унсигезенче шөгыль. Милләтләр дуслыгы . . . . . . . . 30
Татар дөньясы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Унтугызынчы шөгыль. Тылсымлы сүзләр . . . . . . . . 31
Егерменче шөгыль. Уен кораллары. . . . . . . . . . . . . . 32
Егерме беренче шөгыль. Татар халык әкияте . . . . . . 33
Егерме икенче шөгыль. Татар исемнәре . . . . . . . . . . 34
Егерме өченче шөгыль. Сау бул бакча! Исәнме мәктәп! . . . 34
Файдаланылган әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38

Учебное издание

**Шакурова Муслима Магесумовна**
**Гиниятуллина Лилия Миннулловна**

**РОДНОЙ ЯЗЫК – ОН С ДЕТСТВА МНЕ ЗНАКОМ**

Методическое пособие
для воспитателей образовательных организаций дошкольного образования
(для изучающих татарский язык как родной)

(на татарском языке)

Художник А. Б. Шляпкин

Верстка Н.Т. Абдуллиной

Подписано в печать 20.12.2021.
Формат 60×84 1/16. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman
Печать офсетная. Усл. печ. л. 2,3. Уч.-изд. л. 1,3. Тираж 500 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20